**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

дүртенче утырыш
**КАРАРЫ**

10 декабрь 2025 ел **№ 14** Теләче ав.

Теләче муниципаль район Советының 2018 елның 12 апрелендәге 124 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә, **карар итте:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге 124 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә хакында» карарына (Советның 24.08.2018 № 136, 20.11.2019 № 209, 09.10.2020 № 9, 12.11.2021 № 86, 27.12.2021 № 103, 29.04.2022 № 125, 08.09.2022 № 142, 03.11.2022 № 151, 03.05.2024 № 244, 29.10.2024 № 270, 18.04.2025 № 311 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 16 928 сум күләмендә расларга.».

1.2. Карарның 2 номерлы кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы карарына 2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның айлык акчалата хезмәт хакы күләме

| Вазыйфа исемнәре | Коэффициентлар |
|---|---|
| | 8 төркем |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 44 814 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 40 334 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 40 334 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://tulachi.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.




Теләче муниципаль
районы Башлыгы А.Г. Фатхуллин